РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» август 2020 ел г. Альметьевск № 1283

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Башлангыч сыйныф укучыларының бушлай кайнар туклануын оештыру һәм укучыларның кайнар туклануын вакытында тәэмин итү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1581 номерлы карарына (2017 елның 30 октябрендәге 1756 номерлы, 2018 елның 30 мартындагы 425 номерлы, 2018 елның 25 декабрендәге 2254 номерлы, 2019 елның 10 июнендәге 1122 номерлы, 2019 елның 3 сентябрендәге 1633 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 1973 номерлы, 2020 елның 10 мартындагы 323 номерлы, 2020 елның 10 августындагы 1111 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бер укучыга көненә түләүсез кайнар туклану бәясен билгеләргә:

1-4 сыйныф укучылары шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 51 сум 85 тиен.

Көненә бер укучыга туклану бәясен билгеләргә:

шәһәр гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныф укучылары өчен 33 сум 00 тиен;

авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныф укучылары өчен 22 сум 00 тиен.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 3063

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ